**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
«Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кырынды торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 19 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кырынды торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча 2020 елның 19 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта, 17 сәгать 00 минутта, 19 сәгать 00 минутта уздырылган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» Кырынды торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Кырынды авылындагы Советурамы юлы өчен вак таш сатып алу һәм җәю;
2. Кырынды авылында су алу скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу;
3. Беларус 82.1тракторына асылмалы җиһазлар (ротор чапкыч) сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 380 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны – 272 кеше, бу 72 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 272 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кырынды торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» Кырынды торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада

белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, иреклəреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Кырынды авылындагы Совет урамы юлы өчен вак таш сатып алу һәм җәю;
2. Кырынды авылында су алу скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу;
3. Беларус 82.1тракторына асылмалы җиһазлар (ротор чапкыч) сатып алу.

4. Әлеге карарны Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырыга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы И. И. ЗАКИРОВ